КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
Декабристов ул., 2, г. Казань, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«15» февраль 2016-нчы г. № 5-П

Татарстан Республикасы«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы дәүләт хезмәткәре
вазыйфасын башкаручыларның
шәхси мәнфагәтьләре
эштә низагка китерүен (китерү мөмкинлеге булуын)
хәбәр итү тәртибен раслау турында

25-нче декабрь 2008-нче ел №273-ФЗ «Ришвәтчелеккә каршы тору» турындагы федераль канунга, 22-нче декабрь 2015-нче ел №650 «Рәссәй Федерациясендә аерым дәүләт вазыйфаларын алмаштыручы, федераль дәүләт вазыйфаларын башкаручы һәм башка шәхесләрнең шәхси мәнфагәтьләре эштә низагка китерүе» турындагы Рәссәй Федерациясе Президенты күрсәтмәсенә һәм Рәссәй Федерациясе Президентының башка актларына таянып боерам:

1. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкаручыларның, шәхси мәнфагәтьләре низагка китерүн (китерү мөмкинлеге булуын) хәбәр итү тәртибен расларга;
2. Кадрлар булеге (Э.М. Исмагыйлова) «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкаручыларны әлеге боерык белән таныштырырга тиеш. Бу боерык белән танышкан һәр хезмәткәргә имза кую зарури.
3. Кадрлар бүлеге баш белгече (А.А. Хакимов) «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы сайты "Ришвәтчелеккә каршы " дип аталган бүлеккә әлеге боерыкны урнаштырырга тиеш. Рәсми кәгазьне урнаштыру вакыты – боерыкка кул куйганнан сон 1 (бер) эш көне дәвамында.
4. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольда тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Р. Зарипов

«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы боерыгы белән расланган
«15» 02. 2016-нчы ел №5-п

**«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкаручыларның, шәхси мәнфагәтьләре эштә низахка китерен (китерү мөмкинлеге булуын)хәбәр итү тәртибе**

1 Әлеге тәртип «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкаручыларның (түбәндә – дәүләт хезмәткәре), шәхси мәнфагәтьләре эштә низахка китерә яки китерерә алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итү процедурасын регламентлаштыра.

2 Эшкә кагалышлы шәхси мәнфагәтьләр эштә низахка китерә яки китерерә алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итү, (түбәндә - белдерү кәгазе) дәүләт хезмәткәре тарафыннан язма формада, аста беркетелгән кушымта буенча языла һәм «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенә җибәрелә.

3 Агентлык җитәкчесе өч эш көне дәвамында белдерү кәгазен “Ришвәтчелеккә каршы ” профилактика һәм хокук бозуга каршы каралган чаралар өчен жваплы булган кешегә (түбәндә - җаваплы кеше) карау һәм тикшерү өчен җибәрә.

4 Җаваплы кеше эшкә кагылышлы шәхси мәнфагәтьләр низагка китерә яки китерерә алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итүчедән белдерү кәгазендә күрсәтелгән шартлар буенча аңлатма тәлап итергә хокуклы, шулай ук дәүләт хакимиятеннән, башка дәүләт әгъзаларыннан һәм кызыксынган оешмалардан мәгълүмәт алырга мөмкинчелеге бар.

5 Белдерү кәгазьләрен карау нәтиҗәләренә таянып җаваплы кеше дәлилләргә корылган йомгаклау ясый. Белдерү кәгазьләрен, йомгаклауны һәм бу рәсми кәгазгә кагылышлы башка материалларның нәтиҗәләрен җаваплы кеше җиде эш көне эчендә Агентлыкның дәүләт хезмәткәрләренең тәртипләренә булган таләпләр, аларның хокукларын саклау һәм фикер низагын хәл итү комиссиясе рәисенә җиткерә.

6 Әлеге тәртипнең 4-нче пункта күрсәтелгән шартлар буенча сораулар туган очракта, белдерү кәгазьләре, йомгаклау һәм бу рәсми кәгазгә кагылышлы башка материаллар Агентлыкның комиссия рәисенә, белдерү кагәзен кулга алганна соң, 45 көн эчендә тапшырыла ала. Әлеге вакытны Комиссия рәисе озынайтырга хокуклы, тик 30 көннән дә артык түгел.

7 Белдерү кәгазьләре, йомгаклау һәм бу рәсми кәгазгә кагылышлы башка материаллар Комиссия белән Агентлыкның дәүләт хезмәткәрләренең тәртипләренә булган таләпләр, аларның хокукларын саклау һәм фикер низагын хәл итү комиссиясе нигезләнмәсенә таянып карала.

«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы дәүләт хезмәткәре
вазыйфасын башкаручыларның,
шәхси мәнфагәтьләре
эштә низахка китерүен (китерү мөмкинлеге булуын)
хәбәр итү тәртибен раслау буенча кушымта.

______________________

(танышу турында билге)

«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы җитәкчесенә
______________________
______________________
кемнән_______________
(вазыйфа башкаручының
фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**Дәүләт хезмәткәре фазыйфасын башкаручыларның, шәхси мәнфагәтьләре эштә низахка китерүен (китерү мөмкинлеге булуын) хәбәр итү тәртибе**

Мин дәүләт хезмәткәре фазыйфасын башкарганда, шәхси мәнфагәтьләрем эштә низахка китерүе (китерү мөмкинлеге булуын) турында хәбәр итәм (кирәклесен сызырга кирәк).

Дәүләт хезмәткәре фазыйфасын башкарганда, низахка китерүче шартлар:

Низахка китерүче шәхси мәнфагәтьләр эштәге нинди вазыйфа бурычларына йогынты ясыйлар:

Низахны көйләү яки юкка чыгару өчен тәкъдим ителүче чаралар:
Агентлыкның дәүләт хезмәткәрләренең тәртипләренә булган таләпләр, аларның хокукларын саклау һәм фикер низагын хәл итү комиссиясе утырышында катнашу яки катнашмау (сызырга кирәк)

«___» ______2016-нчы ел ____________ ________
(белдерү кәгазен юнәлтүченең имзасы) (имза чишелеше)